СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2019 п.г.т. Алексеевское № 221

**2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты турында**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм муниципаль берәмлек уставының 75 һәм 76 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге

**Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карар чыгарды**:

1. 2020 елга Алексеевск шәһәр җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1.1 Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 43250,90 мең сум күләмендә;

1.2 Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 43250,90 мең сум күләмендә.

1.3 2020 елга Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты кытлыгы нульгә тигез.

2. 2021 һәм 2022 еллар план чорына Алексеевск шәһәр җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

2.1 2021 елга Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 43705,60 мең сум һәм 2022 елга 44231,20 мең сум күләмендә;

2.2 Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме:

- 2021 елга 43705,60 мең сум күләмендә.
- 2021 елга 44231,20 мең сум күләмендә

2.3 2021 елга һәм 2022 елга Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты кытлыгы нульгә тигез.

3. 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Алексеевск шәһәр җирлеге бюджетында 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына керемнәрнең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

5. Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

6. Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

7. Бюджет ассигнованиеләрен 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясе төрләре төркемнәренең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары буенча бүлүне әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

8. 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Алексеевск шәһәр җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

9. 2020 елга Татарстан Республикасы акчалары исәбеннән җирлекләрнең район финанс ярдәме фонды дотацияләре күләмен 620,8 мең сум күләмендә, 2021 елга 652,6 мең сум, 2022 елга 644,0 мең сум күләмендә расларга.

10. 2020 елга бюджет тәэмин ителеше буенча җирлекләрнең финанс ярдәме район фондыннан дотацияләр күләмен 7883,0 мең сум, 2021 елга 7147,3 мең сум күләмендә, 2022 елга 6316,0 мең сум күләмендә расларга.

11. Алексеевск шәһәр җирлегенең башкарма комитеты 2020 елда һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләре санын, шулай ук аларны тотуга чыгымнарны арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

12. Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитетының резерв фонды турындагы нигезләмәне 7 нче кушымта нигезендә расларга.

13. 2020 елга Алексеевск шәһәр җирлеге керемнәрен бүлү нормативларын 8 нче кушымта нигезендә расларга.

14. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары Алексеевск шәһәр җирлеге бюджетын, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә бюджетны үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

15. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**